Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының илле икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

22 май, 2025 ел № 409

2027 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы, 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 58 номерлы карары белән (2019 елның 24 октябрендәге 218 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2022 елның 24 ноябрендәге 197 номерлы карары белән расланган 2027 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Кеше капиталы» бүлегендә:

- «Сәламәтлек саклау» бүлекчәсенең түбәндәге эчтәлекле 19 һәм 20 пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19 | Туклану режимын һәм характерын оптимальләштерүне, шулай ук халыкның төрле төркемнәрен сәламәт туклану мәсьәләләре буенча, шул исәптән әлеге мәсьәләләр белән | 2027 | ЦРБ ПМР, ИК ПМР | ТР бюджеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шөгыльләнүче оешмалар катнашында, белем бирүне һәм укытуны күздә тоткан барлык яшь төркемнәрендәге халыкны сәламәт туклануны тәэмин итү | | | |
| 20 | Хәрәкәт активлыгын арттыру буенча чаралар эшләү, ул гражданнарның сәламәтлеген саклауның мөһим шарты булып тора, моңа актив яшәү рәвешен пропагандалау һәм стимуллаштыру, физик культура мәсьәләләрендә халыкның белем алуы да керә; дәвалау физкультурасын һәм сәламәтлекне саклауга юнәлдерелгән физик культураны үстерү | 2027 | ЦРБ ПМР,<br>ИК ПМР | ТР бюджеты |

- «Спорт» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Питрәч авылында ябык футбол манежы һәм универсаль спорт мәйданчыклары төзүне үз эченә алган үзәк стадионны реконструкцияләү | 2027 | Мәгариф бүлеге, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге | ТР бюджеты |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, бюджет, салымнар һәм финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов